# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

"Татарстан Республикасы халыкларының телләре турында" Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында

"Татарстан Республикасы халыкларының телләре турында" Татарстан Республикасы Законына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1. I бүлекнең 1 статьясында "җыелмасы" дигән сүздән соң "Татарстан Республикасы Конституциясеннән", дип өстәргә.

2. I бүлекнең 3 статьясын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Тигез хокуклы татар һәм урыс телләре Татарстан Республикасында дәүләт телләре булалар".

3. I бүлекнең 5 статьясындагы 1 пунктына түбәндәге эчтәлекле җөмлә өстәргә:

"Гражданнарга туган телләреннән файдалану мөмкинлеге гарантияләнә".

4. II бүлекнең 9 статьясындагы 2 пунктына түбәндәге җөмләне өстәргә:

"Татарстан Республикасы гражданнары мәктәптә туган телләрендә белем алырга хокуклылар".

Татарстан Республикасы
Президенты — М.Шәймиев

Казан шәһәре,
1996 елның 28 марты
N 488